**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 30 марты** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 1 нче номерлы "«Яңа Имән авыл җирлеге Күтәмәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле 2023 елның 22 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1.«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле авылы торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 22 ноябрь 2023 елнын 2нче номерлы карарына узгәрешләр кертү турында чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Күтәмәле авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Күтәмәле торак пункты чикләрендә юлларны кардан чистарту (тракторчы хезмәтләре өчен түләү);

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Күтәмәле авылында триммерлар һәм генератор өчен запчасть һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу; МТЗ 82.1 тракторына хезмәт күрсәтү(ягулык-майлау материаллары, өстәмә асылмалы, тагылма җиһазлар, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү); халык күплэп ял итә торган урыннарны һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (сабантуй мәйданына төзү материаллар, сэхнэ сатып алу , скамейкалар сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү );

4. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары белән тәэмин итү (Күтәмәле авылында янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүченең хезмәте өчен түләү)

5. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Күтәмәле авылында - “Шамгун”, “Миннәхмәт” чишмәләрен тозекләндерү (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;

6. Яр буйларын, сулыкларны чистарту (Күтәмәле авылы сулыкларында агачларны кисү,шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

7. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аның янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (Күтәмәле авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарның һәйкәлен ремонтлау)?";.

2. Әлеге карарны Яңа Имән авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Гараев Р.Ф.